# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге составына керүче Сакон авылы торак пунктында**

17 декабрь 2021 е. № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге составына керүче Лебяжье авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Лебяжье авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган 1 төркем инвалидлардан, уку студентларыннан, гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
   - җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
   - техниканы – тракторны карап тоту;
   - урамнарны яктырту;
   - балалар мәйданчыгын киртәләү;
   - җирләү урыннарын төзекләндерү;
   - су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авылы, Үзәк ур., 27А йорт, Лебяжье авыл җирлеге адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Лебяжье авыл җирлеге башлыгы** **Д.Ә.Гыйләҗев**